КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 февраль г.Казань № 82

«Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын уздыру көннәрендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын уздырганда иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Күнегүләр һәм ярышлар уздыру көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр спорт объектларына якын территорияләрдә урнашкан сәүдә объектларында алкогольле продукцияне ваклап сату кушымта нигезендә рөхсәт ителми дип билгеләргә.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты белән берлектә, кертелә торган чикләү турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына килешү буенча йөкләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 15 февраль, 82 нче
карарына кушымта

Спорт объектларына якын территорияләрдә урнашкан сәүдә объектларының урнашкан урыны

| Т/с | Спорт объектының адресы һәм исеме | Алкогольле продукцияне сатуны чикләү даталары | Сәүдә объектлары адреслары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | “Татнефть Арена” боз спорт сарае, Казан шәһәре, Чистай урамы, 42 йорт | 19.02.2024 – 23.02.2024 | Казан шәһәре, Мусин урамы, 1, 9А йортлары; Чистай урамы, 25, 27А, 33А, 33В, 36, 38, 40, 43, 43А, 47А, 53А йортлар |
| 2. | «Казан теннис академиясе» укыту-спорт комплексы, Казан шәһәре, Оренбург тракты, 101 йорт | 20.02.2024 – 03.03.2024 | Казан шәһәре, Академик Парин урамы, 16, 22 йортлар |
| 3. | «Ак Барс» көрәш сарае, Казан шәһәре, Фатыйх Әмирхан пр., 1Г йорт | 22.02.2024 – 23.02.2024 | Казан шәһәре, Фатыйх Әмирхан проспекты, 1, 1А, 1Е йортлар; Сибгат Хәким урамы, 40А, 44 йортлар; Алексей Козин урамы, 2 йорт |
| 4. | «Казан дәүләт циркы» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе, Казан шәһәре, Меңеллык урамы, 2 йорт | 24.02.2024 – 26.02.2024 | Казан шәһәре, Ташаяк урамы, 2а йорт |
| 5. | «Бәкер Рәмиев исемендәге ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк , Казан шәһәре, Спартак урамы, 2 йорт | 21.02.2024 – 26.02.2024; 28.02.2024 – 02.03.2024 | Казан шәһәре, Спартак урамы, 2, 2А, 6 йортлар; Һади Такташ урамы, 2, 21, 30, 54А, 77 йортлар; Островский урамы, 102 йорт; Сәлимҗанов урамы, 2, 6, 12А, 15/8Б, 17 йортлар; Миңнуллин урамы, 14/56 йорт |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 6. | «Хезмәт резервлары» спорт-сәламәтләндерү комплексы, Казан шәһәре, Николай Ершов урамы, 7 йорт | 27.02.2024 – 29.02.2024 | Казан шәһәре, Николай Ершов урамы, 5, 7Г, 8 йортлар |
| 7. | «Зилант» боз сарае» укыту-спорт комплексы, Казан шәһәре, Мәүлетов урамы, 17Б йорт | 19.02.2024 – 20.02.2024 | Казан шәһәре, Гарифьянов урамы, 4, 28А, 28Б йортлар; Сыртланова урамы, 8, 16 йортлар; Мәүлетов урамы, 16Б, 17, 24А, 29, 29А, 31В, 42, 46, 48/6 йортлар; Бертуган Касыймовлар урамы, 22/7 йорт; Профессор Камай урамы, 1, 8, 8А, 9 йортлар |
| 8. | «Искәндәр» футбол-регби манежы, Казан шәһәре, Маршал Чуйков урамы, 8 йорт, 2 корпус | 19.02.2024 – 20.02.2024 | Казан шәһәре, Короленко урамы, 28Б, 30 йортлар; Голубятников урамы, 2 йорт; Маршал Чуйков урамы, 3, 4, 9,11А йортлар |
| 9. | «Урам» яшьләр экстрим-паркы, Казан шәһәре, Кремль яр буе, 33 йорт | 22.02.2024; 28.02.2024; 29.02.2024 | Казан шәһәре, Подлужная урамы, 56 йорт |
| 10. | «Иннополис» спорт комплексы, Иннополис шәһәре, Спорт урамы, 107 йорт | 20.02.2024 – 23.02.2024 | Иннополис шәһәре, Спорт урамы, 100, 101, 104, 108, 110, 118, 126 йортлар |

________________________